*Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение Большеелгинский детский сад «Умырзая» Рыбно – Слободского муниципального района Республики Татарстан*
*Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты "Умырзая"*
*Олы Елга балалар бакчасы мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениясе*

# «Сөйләм эшчәнлегендә театр сәнгатенең әһәмияте» проекты буенча эшләнелгән эшләр.

Башкаручы: Насибуллина Миләүшә Рәүф кызы.

Балаларның  театр сәнгате үзенчәлекләрен үзләштерү аша  сөйләм телен үстерү максаты кысаларында, “Умырзая” балалар бакчасы тәрбияләнүчеләре, тәрбиячеләр, ата – аналар,  китапханә, “Туган якны өйрәнү” музее җитәкчеләре  белән берлектә   түбәндәге эш нәтиҗәләренә ирештем.

| Эшчәнлекнең исеме | Раслаучы документлар |
|---|---|
| Педагогик киңәшмәдә чыгыш: “Балалар бакчасында курчак театры” | Кушымта №1 |
| Төркемнәрдә театральләшкән уен һәм спектакль өчен почмак булдырылды. “Теремкәйгә рәхим ит”. |  |
| Сюжетлы  - рольле уеннар тупланмасы булдырылды. | Кушымта №2 |
| Балалар бакчасында   театраль тамашалар кую өчен сценарийлар төзелде. | Кушымта №3 |
| Оешкан белем бирү эшчәнлекләрендә һәм режим моментларында театрның бармак, өстәл, бибабо, курчак, фланель төрләре кулланылды. | Кушымта №4  |

| | |
|---|---|
| |     |
| Балалар белән үткәрү өчен сулыш, артикуляцион гимнастик күнегүләр | Кушымта №5 |

| | |
|---|---|
| җыелмасын булдырылды, кулланышта тора. | |
| Ата – аналар өчен мастер класс. “Театр өчен курчакны ничек эшләргә?” | Кушымта № 6 |
| Ачык ишекләр көне. “Өч кыз” татар халык әкиятен эти – әниләргә тәкьдим итү. | Кушымта №7  |
| Балаларның театр эшчәнлегендә иҗади сәләтләрен үстерү өчен диагностика биремнәре әзерләнде. | Кушымта № 8 |

**Кушымта №1**

**“Курчак театры балалар бакчасында”**

Курчак театры нәни тамашачыларга сәнгати чаралар комплексы ярдәмендә уңай тәэсир итә. Курчак театрының спектакльләрен күрсәткәндә әдәби сүз һәм күрсәтмәлелек – курчаклар, декоратив бизәлеш, музыка кулланыла. Театрны урынлы куллану, балалар бакчасының көндәлек эшендә балаларның аң – белем, әхлак, эстетик тәрбиясендә зур ярдәм күрсәтә. Мәктәпкәчә чор балалары курчак театры спектакльләрен бик яратып карыйлар. Ул аларга якын, аңлаешлы, аңнарына тизрәк барып җитә. Балалар ширмада таныш, яраткан курчаклары: аю, куян, песи, этнең хәрәкәтен күреп, тагын да ныграк кызыксыналар.

Ләкин курчак театрын күңел ачу буларак кына кабул итәргә ярамый.Аның тәрбияви әһәмияте бик мөһим, чөнки бу вакытта балаларның тирә – якка мөнәсәбәте формалаша, характеры, кызыксынулары арта.

Менә шушы яшьтә дуслык, яхшылык, хезмәт сөючәнлек турында театрлар күрсәтергә кирәк. Күп әсәрләрдә бу ачык чагыла: А Алишның “Бикбатыр белән Биккуркак”, татар халык әкияте “Икмәк”. Шул ук вакытта ялкаулар, мактанчыклар тәнкыйтьләнә, аларның үзләрен тотышы балаларда тискәре мөнәсәбәт уята. (“Кирлемән әкияте”).

Балалар спектакль дөньясына тиз “кереп китәләр”, курчакларның сорауларына җавап бирәләр, аларның йомышларын үтиләр, киңәш

бирәләр, куркыныч килүен кисәтәләр, спектакль геройларына ярдәм итәләр. Спектакльдә күренешләрнең гадәти булмаган булуы аларны биләп ала һәм балаларны әкияти дөньяга күчерә.

Курчак театрының барлык төрләре дә даими рәвештә алып барылырга тиеш. Балалар бакчасында театрларның иң популяр саналганы: фланель, уенчык, өстәл, бармак, курчак театрлары. Курчак театрында музыкаль бизәлеш булу, әкиятне аеруча күңелле итә.

1.Фланель театрын әзерләве һәм балаларга күрсәтүе гади эшчәнлек. Картинкалар һәм декорацияләр яссы, аларны өстәлгә куелган махсус фланель тактада күрсәтәләр.

2. Уенчыклар театрында гади уенчыклар һәм балалар курчаклары кулланыла. Әкиятне күрсәткәндә бернинди кулдан ясалган җиһаз таләп ителми, шуңа күрә әзерлек эше җиңеләя.

3.Курчак театрында тәрбияче курчакны кулга киеп, курчак белән идарә итә, аның белән сөйләшә. Тәрбиячене̧ң бар осталыгы курчаклар белән идарә итүгә юнәлтелә. Курчак, аның үзен тотышы, хәрәкәте аркылы балалар белән аралашу барлыкка килә. Эшнең мондый формалары бик кызыклы һәм файдалы, шуның өчен олылар тарафыннан хуплау сорый. Театр балаларның иҗади сәләтләрен үстерә, әдәби әсәрне аңларга ярдәм итә. Курчак театрын куюга зур игътибар белән карарга кирәк. Эшне җиренә җиткереп, югары педагогик дәрәҗәдә башкару сорала, курчак театрының балаларны театр һәм сәнгатькә тартуның беренче юлы булып торуын онытмаска кирәк.

**Курчак белән ширмасыз күнегү–уен**

Һәр балалар бакчасында, гаиләдә уенчыклар арасында кулга киелә торган курчакларны күрергә мөмкин. Алар курчак театры “актерлары” – бабай, әби, кыз, малай, бүре, куян . Театр курчаклары гади курчаклардан гәүдәләре булмау белән аерылып тора. Гәүдәне, курчак белән идарә итүченең кулына кидерелә торган күлмәк – перчатка алыштыра. Курчакның муенына бармак кертү өчен патронка беркетелә. Муенның ян кырыйларына күлмәк – перчатка ябыштырыла. Күлмәк җиңнәренә патронкалар белән курчак кулы беркетелә. Курчак хәрәкәтләнсен өчен, күрсәткеч бармакны муенның патронкасына кидерәләр, ә зур һәм урта бармакны кул патронкасына кидерәләр. Кулга киелгән курчакны бит ягы белән үзеңә каратырга һәм түбәндәге күнегүләрне эшләргә кирәк.

1.Курчак берничә тапкыр башын алга исен һәм гәүдәсе белән “баш ию” хәрәкәте ясасын. Беренче очракта күрсәткеч бармакның ике буыны бөгелә, икенче очракта бармаклар туры кала, кул чугы бөгелә.

2.Курчак уңга – сулга борыла, кулларын чаба, як – якка җәя, өскә күтәрә, алга суза.

3.Курчак кочаклый, биттән кулы белән сыпыра, колакка сүз әйтә, тәрбиячегә сыена.

Курчак белән тәрбияче уенчыклар янына килә, берсен ала, аны башкаларга күрсәтә һәм урынына куя. Күнегүләр берничә тапкыр кабатлана. Соңрак күнегүләр сүз белән аралаштырыла. Мәсәлән, курчак флагчыкны ала һәм саный – бер, ике, өч, дүрт, биш. Ширманың булмавы тәрбиячегә курчак

белән балалар янына якын килергә, күрешергә, башыннан назларга, сөйләшергә, аннан ягымлы көләргә, гомумән, тәрбияче белән бала арасында бәйләнешне ныгытырга мөмкинлек бирә.

## Ширма һәм декорацияләр

Курчак театрының сәхнәсе – ширма. Ширмада декорацияләр куела, спектакль күренеше шунда бара. Ширма артында курчак белән идарә итүчеләр тора. Ширмалар ясалышы буенча төрле булырга мөмкин, аларны зур, катлаулы итү кирәк түгел. Мәсәлән, ике шкаф, ике урындык арасына, ә җәй көне ике агач арасына агач рейка ( 1.5 м озынлыгы, 160 см. биеклеге) беркетергә була. Рейкага калын материал беркетелә, идәнгә кадәр төшерелә. Ширма шома, тыныч тондагы тукыма белән каплана. Әгәр ширмада җәйге урман, болын булса, тукыманың берничә урынына чәчәкләр; көз булса – сары яфраклар; кыш икән – кар бөртекләре беркетелә. Бик аз очракта гына курчак театры буш ширмада үтә. Гадәттә аны декорацияләр белән бизиләр. Ширмага спектакль өчен кирәк булган предметлар гына куела, алар барысы да кулланылырга тиеш. Әгәр агач, куак, төп куйсак – уйнаучы курчак агач артына кача, төпкә утыра ала. Ширманы артык предметлар белән тутырырга ярамый. Декорацияне беркетү өчен ширманың алгы горизонталь рейкасына бер сантиметр диаметрлы тишекләр һәм шул ук зурлыктагы агач таяклар ясыйлар. Таяклар тишеккә өч сантиметрга тыгыз кереп утырырга тиеш, аңа спетакль өчен кирәкле детальләр беркетелә. Декорацияләрне курчакларга караганда зуррак итеп ясарга кирәк. Спектакль вакытында ширмада чын предметлар да кулланырга мөмкин, мәсәлән курчак кечкенә чын китапны укый, кечкенә чокырдан чәй эчә һәм башка хәрәкәтләр ясый.

## Курчак белән ширмада күнегүләр

Ширма әзер булгач, курчаклар белән күнегүләргә күчәргә мөмкин. Мәсәлән, курчакның йөреп барганын күрсәтер өчен, бер яктан икенче якка авыштырып, ритмлы алга таба хәрәкәтләндерергә кирәк. Кыз – курчак йөгергәндә бу хәрәкәтләр тизләтелә. Хәрәкәтләрне төгәл үтәр өчен, берничә тапкыр төрле курчак белән ширмадан йөреп үтәргә кирәк. Курчаклар җир астыннан чыкан кебек түгел, ә салмак кына әкренләп чыгарга тиеш: элек башы күренә, аннан иңбашы, күкрәк, тезләрдән югары өлеше күренә. Ул һәрвакыт шушы югарылыкта булырга тиеш. Ширмадан киткәндә дә әкренләп югалырга кирәк. Тәрбияче курчакны ширмага алып чыга, уртада туктала һәм түбәндәге күнегүләрне эшли – баш ия, билдән бөгелә, кулларын як – якка җәя, өскә күтәрә һәм башка кирәкле хәрәкәтләрне башкара. Соңрак предметлар белән күнегүләр үткәрелә башлый, мәсәлән, шакмакны өслеккә куярга, астан тамашачылар күрмәслек итеп буш кул белән тотып торырга, курчакны шакмак янына якын китерергә һәм аның кулы белән алырга кирәк. Курчак белән идарә итүче тәрбияче башка урынга күчә һәм шакмакны ширмага куя. Әгәр курчак ширмадан предмет алса, гәүдәне бөтен өлеше белән аска төшерергә кирәк түгел. Гәүдәнең өске әлешен генә бөкләргә

кирәк, моңа курчак белән идарә итүче кул чугын бөгү белән ирешә ала. Курчакны утыртырга да мөмкин. Әгәр аяклары булса, тамашачыга йөзе белән каратып, ширма аша аякларын салындырып утыртырга кирәк. Әгәр курчак ятарга тиеш булса, элек курчакны утырталар, аннан башын ширмага куялар. Йоклаганны күрсәтергә кирәк булса, тамашачылар ачык күзләрне күрмәсен өчен, курчакны арты белән ширмага яткыралар.

Курчак театрында курчак белән идарә итүчеләргә икешәр курчак белән эшләргә туры килә. Өйрәнчекләргә ике курчак белән эшләргә ярамый, элек әркенләп һәр кулны күнектерергә кирәк. Моның өчен бер тәрбияче курчакны уң кулына, икенче тәрбияче сул кулына кия һәм ширманың ике ягыннан чыгалар. Уң кулында курчак булган тәрбияче ширманың уң ягына баса, сул кулында курчак булганы сул якка баса. Курчаклар бер – берсенә якын киләләр, туктыйлар, кул бирешеп күрешәләр, кочаклашалар. Бер – берсеннән аерылып азрак кире китәләр. Сөйләшүче курчак акрын гына хәрәкәтләнә, тыңлаучы курчак дустына карап хәрәкәтсез тора.

## Спектакль буенча эш

Балаларга курчаклар белән ничек эшләү күнегүләрен өйрәткәч, пьеса куярга әзерләнергә мөмкин. Беренче эш итеп пьеса барлык катнашучылар алдында укыла, күренеш вакыты һәм урыны ачыклана, катнашучыларның образы һәм бер – берсенә булган мөнәсәбәте сөйләшенә, рольләр бүленә, әзерлек эшләре башлана. Укыган вакытта пьеса өлешләргә бүленә, детальләп тикшерелә. Өстәл тирәли коллектив укудан башка, һәр бала үз роленең сүзләрен өйрәнә. Һәр персонаж өчен үз характерлы тавышы, сөйләшү, йөрү манерасын табарга кирәк. Ясалма тавыш балаларны курчакның үзе сөйләвенә ышандыра алмый. Аның өчен сөйләм гади һәм сәнгатьле булырга тиеш. Соңрак курчаклар белән ширмада эшли башларга була. Текстны яттан өйрәнгәнче, аны үз сүзләрең белән сөйләргә мөмкин. Бу балаларга иҗат итүдә иркенлек бирә һәм әкренләп рольгә керергә ярдәм итә. Шулай ук балалар курчакның каян чыгуын, кайда тукталуын, нәрсә эшләвен, ничек кереп китүен аңлашалар. Ширмада берничә курчак уйнаса, аларның һәрберсенә үз урынын билгелиләр, шул ук вакытта ширманың һәр уен өлешен кулланырга кирәк, курчакларны бер урында туплап тотарга ярамый. Аларның күчеп йөрүе нинди дә булса максат белән эшләнергә тиеш. Курчаклар урынын алыштыру белән, курчак белән идарә итүчеләр дә урыннарын алыштыралар. Ширмадагы курчак һәр нәрсәгә игътибар итәргә тиеш: башка курчакның килүенә, китүенә, бер – берсенә эндәшүгә, сөйләшүенә. Курчакның карау, тыңлавын күрсәтәсе булса, гәүдәне азрак борып, башын чак кына бөкләргә кирәк. Әгәр курчак тамашачылар белән сөйләшә икән, ул залның төрле урынында утырган балаларга мөрәҗәгать итә, әгәр бер бала белән икән, нәкъ шул бала белән генә сөйләшә. Төгәл хәрәкәтләр курчакны тере, мәгънәле итеп күрсәтә һәм балалар игътибарын җәлеп итә. Әгәр курчак хәрәкәтсез бер урында гына басып торса, ул кызыксызга әверелә, аңа карыйсы да килми.

Музыка курчак театрының аерылгысыз бер өлеше булып тора. Ул спектакль башланганда һәм аерым күренешләрдә кулланылырга мөмкин.

Музыка курчаклар хәрәкәтенең ритмлы булуын күрсәтә. Бик сирәк спектакль гына җырсыз һәм курчаклар биюеннән башка үтә, чөнки җыр – биюне балалар бик яраталар. Пьесаны тулысынча кабатлау өчен курчаклар һәм бизәлеш ягыннан әзерлек кирәк. Текст яттан өйрәнелергә тиеш. Соңгы репетицияләрдә театрны кую буенча техник бурычлар бүленә: бизәлешне көйләп кую, курчаклар белән идарә итүдә ярдәм. Генераль репетицияләрдән соң әкиятне балаларга күрсәтергә мөмкин. Спектакльне ябык бинада һәм ачык һавада күрсәтеп була. Ике очракта да яктылык ширмага тамашачы ягыннан төшәргә тиеш. Ширмадан ике – өч метр ераклыкта балалар өчен урындыклар куела. Балалар үз урыннарына узганда ширма артындагы курчакларны күрмәскә тиеш. Курчак белән идарә итүчеләр баскан хәлдә эшлиләр. Ширма артында аларның хәрәкәтен чикләүче артык предмет булырга тиеш түгел. Курчаклар куелырга тиешле өстәл яки урындыклар ширмадан бер метр ераклыкта торырга, өстенә йомшак җәймә ябылырга тиеш, чөнки курчак яки предметны өстәлгә куйганда, тавыш чыгарга мөмкин. Курчак белән идарә итүчеләр аягына җиңел, йомшак аяк киеме кисә яхшырак булыр. Әгәр инде текстны яттан өйрәнү проблемасы туган икән, аны магнитофон тасмасына яздырырга кирәк.Ул вакытта курчакларның ширмадагы хәрәкәтен магнитофондагы фонограммага кабатларга кирәк булачак.

## Кушымта №2

1.Сюжетлы-рольле уен : “Чулман елгасы буйлап сәяхәт”



Уенның актуальлеге**:** Кече яшьтән балаларда туган төбәгебезгә карата мәхәббәт уяту һәм анда яшәүче халыкның көнкүреше, шөгыле турында мәгълүмат бирү бик әһәмиятле булып тора. Чөнки сюжетлы - рольле уеннар әйләнә – тирә чынбарлыкның күренешләрен, өлкәннәрнең тормышын һәм эшчәнлеген чагылдыра. Шуңа күрә, туган төбәгебездә яшәүче өлкәннәрнең хезмәтен чагылдырган “Чулман елгасы буйлап сәяхәт” сюжетлы-рольле уены уйнау мөһимлеге туды. Баланың уен процессында бер

– берсенә карата мөнәсәбәте, иркен аралашуы, гамәлләрендә иреклелек күзәтелә. Уенда баланың иҗади мөмкинлекләре киңәя, фантазияләре байый, төрле образга кереп, рольләрне оста башкара ала. Төрле тормыш ситуацияләрен уйнап, балалар килеп туган каршылыкларны җиңәргә өйрәнә, дуслык атмосферасы тудыра.

Уенның максаты: Балаларның практик эшчәнлегенә нигезләнеп, танып белү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль активлыкларын һәм иҗади фантазияләрен баету, елга, диңгез белән бәйле һөнәрләр турында белемнәрен үстерү.

Уенның бурычлары: - Социаль чынбарлык күренешләре белән танышу аша, сюжетлы - рольле уен эчтәлеген баету;
- елга, диңгез һәм аның белән бәйле һөнәрләр турында күзаллауларын һәм белемнәрен үстерү, “диңгезче” сүзенең мәгънәсен төшендерү;
- бәйләнешле сөйләм үстерү, сүзлек запасын киңәйтү;
- танып белү активлыгын үстерү, тәҗрибәләренә таянып, әйрәнә – тирә турында күзаллауларын тулыландыру;
- уенны мөстәкыйль оештыру күнекмәләрен ныгыту;
- хезмәткә карата мәхәббәт тәрбияләү.

Уенда катнашучылар: балалар, тәрбиячеләр, ата – аналар, социаль партнерлар.

Җиһазлар: Агач ширма, штурвал, якорь, коткару түгәрәге, жилетлар, күзәтү трубасы – бинокль, сары һәм кызыл төсле сигнал флагчыклары, сырлы футболка, баш киеме, рупор, компас, рация, “Балыкчылар өчен” набор, уенчык балыклар, чиләк, пассажирлар өчен билетлар, кечкенә урындыклар, табиб киеме, “Табиб” наборы, пешекче - кок киеме, “Ашханә” наборы, идән юу наборы.

Уенга алдан әзерлек эшләре: Сюжетлы рольле уенны иллюстратив материаллар белән баету, методик китаплар һәм матур әдәбият әсәрләре сайлау. Балалар белән авылның Әмикъ күленә, буа буена сәяхәт. “Һөнәрләр” темасына рәсемнәр карау. “Диңгезче”, “Балыкчы белгечлеге” турында презентация карау.
**Үткәрелгән әңгәмә темалары**: “Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар”, “Балыкчы һөнәре”, “Корабта кемнәр йөзә?”, “Йөзү серләрен беләсеңме?”, “Давыл күтәрелгәндә”, “Су транспорты”, “Диңгезчегә нинди әсбаплар кирәк?”, “Иң кирәкле һөнәр”, “Без әти белән балыкка бардык”.
**Дидактик уеннар:** “Кем күбрәк гамәл әйтә?”, Кемгә нәрсә кирәк?”.
**Нәфәсати тәрбия:** “Балыклар”, “Сигезаяк” әвәләү.
**Тәҗрибә:** “Суның үзенчәлекләре”.
**Хәрәкәтле уеннар:** “Море волнуется”, “Яр-су”, “Су астында”, “Аквариум”.
“Балыклар” буяулы рәсемнәрен (раскраскалар) буяу.

**Кисеп ябыштыру**.“Ватанны саклаучылар көненә открытка”
**Кул эше:** “Кораб”, “Көймә” корылмалары.
**Оригами:** “Көймә”.
**Музыка тәрбиясе:** Айдар Минһаҗев сүзләре, Әлфия Һадиева көе: “Күңелле сәяхәт” җыры.
**Ата-аналар белән эш**: “Балагыз өйдә ничек һәм нәрсә белән уйный?” Анкета үткәрү.
“Баланы һөнәрләр белән таныштырабыз” журналы тәкъдим итү.
“Балаларны диңгез, елгалар белән таныштыру” турында күрсәтмә материаллар-папкалар әзерләү.
“Минем яраткан һөнәрләрем” рәсемнәр күргәзмәсе оештыру.
Ата-аналар җыелышында диңгездә матрос булып хезмәт иткән әтинең (Хәйретдинов Айрат) чыгышын, аның киңәшләрен, искәртмәләрен тыңлау.
**Тәрбиячеләр белән эш.**
“Диңгездә(елгада) сәяхәт”, “Су патшалыгында” өзлексез белем бирү эшчәнлеге.
Ата-аналар өчен белешмәлекләр ясау.
Ата-аналар өчен. “Баланы һөнәрләр белән таныштырабыз” журналы белән танышу
Ата-аналар өчен: “Су белән чыныктыру ысуллары турында” күрсәтмә материаллар тәкъдим итү.
“Татарстандагы сулыклар”, “Картадагы зәңгәр төс” балалар өчен презентацияләр әзерләү.
“Минем авылым сулыклары”, “Балык тоту” - рәсемнәр бәйгесе үткәрү. Әлеге рәсемнәрдән күргәзмә оештыру.

Уенның тасвирламасы: “Чулман елгасы буйлап сәяхәт” сюжетлы уенында балалар туган төбәгебездә урнашкан Чулман елгасы һәм аның белән бәйле булган элеккеге һәм заманча һөнәр ияләре турында белемнәрен тирәнәйтәләр. Уен тематикасын чагылдырган модуль балаларның күзаллавын, фантазияләрен, сүзлек запасын баета. Уен атрибутларның тулылыгы, матурлыгы балаларда төрле тормыш ситуацияләрен уйнау теләген үстерә. Сюжет линиясен төрлеләндерү аша, балаларның иҗади мөмкинлеге ачыла. “Нәни коткаручылар”, “Балык тоту”, “Сак булыгыз, давыл!”, “Күңелле сәяхәт” ситуацияләрен кызлар да, малайлар да үзара иркен аралашып, дус – тату уйныйлар. Бирелгән модуль төрле уеннарны үз эченә ала, һөнәр ияләре белән якыннан танышырга ярдәм итә.
Уенда рольле гамәлләр :
Капитан - ул командага әмер бирә, төрле ситуацияләрне дөрес чишә, дөрес итеп маршрутны билгели.
Матрослар - капитанның әмерләрен үти.
Штурвалчы – корабны йөртә.
Механик – корабны төзәтә.
Табиб – йөзү вакытында чирлеләрне дәвалый.

Капитан ярдәмчесе – кораб һәм андагы кагыйдәләр белән пассажирларны таныштыра.
Пешекче – кок – ашханәдә керүчеләргә азык әзерли.
Официант – ашханәдә хезмәт күрсәтә.

Уен ситуацияләре: “Балык тоту”, “Пароходта сәяхәт”, “Көймә төзәтү”, “Давыл башланды”, “Чунга – Чанго белән очрашу”,

“Пароходта сәяхәт” уен ситуациясенең барышы:
**-**Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, җавабын кем белер икән?
Булмаган җире сирәк,
Үзе һәрвакыт кирәк.(Су
-Әйе, дөрес.
Фикер алышу (Җир шары макеты, глобус ярдәмендә):
-Анда коры җир күбрәкме, әллә сумы?
-Су кайларда була?
-Су турында ниләр беләсез? Суда сәяхәт иткәнегез бармы? Мин сезне сәяхәткә чакырам. Нәрсәдә сәяхәткә чыгарбыз? (Корабта) Безгә сәяхәткә чыкканчы, рольләрне бүлешергә кирәк.
Корабта капитан булырга тиеш. Әйдәгез, аны санамыш ярдәмендә сайлыйбыз. (Бер бала санамыш белән капитан сайлый). Капитан -Павел. Капитан нишли? Ул командага әмер бирә, төрле ситуацияләрне дөрес чишә, дөрес итеп маршрутны билгели. Штурвалчы штурвал белән идарә итә. Пешекче-кок Фәридә булыр, ул корабтагыларга ашарга әзерли. Диспетчер - җиргә корабтагы бар мәгълуматны җиткереп торучы, чиста аңлаешлы сөйләм белән һәрчак элемтәдә булырга тиеш. Кемнәр матрос була? Матрос – Ильяс һәм калган балалар. Пассажирлар корабта сәяхәткә чыгалар. Капитан команда бирә, бинокльдән карап юнәлеш билгели. Штурвалчы кораб йөртә, штурвал бора. Тукталышта бар пассажирлар чыга, йөриләр, саф һава сулыйлар. Матрослар, моряклар корабта җыештыралар, трап алып куялар, палуба юалар, капитан әмерен тыңлап, башкаралар. Пешекче-кок команда өчен ашарга әзерли. Команда ял итә, кокның тәмле төшке ашын ашый. Капитан картадан корабның юнәлешен карый. Барысы да ярга чыгалар.
Көтелгән нәтиҗәләр: Сюжетлы - рольле уенга балаларны, ата – аналарны җәлеп итә алдык. Балалар уен аша, төрле һөнәр ияләре һәм аларның эшчәнлекләре турында белемнәрен ныгыттылар. Шулай ук, балалар бербөтен булып, иптәшләренең фикерләрен тыңлап, дустанә мөнәсәбәт саклап, уйнау тәҗрибәсе тупладылар. Уен сюжетларын уйлап чыгарып, балаларның фантазияләре, диалогик сөйләмнәре, күзаллаулары, сүзлек байлыклары үсә.

2.Сюжетлы-рольле уен: **“Терлекчелек”**



Уенның актуальлеге: Кече яшьтән балаларда туган төбәгебезгә карата мәхәббәт уяту һәм анда яшәүче халыкның көнкүреше, шөгыле турында мәгълүмат бирү бик әһәмиятле булып тора. Чөнки, сюжетлы - рольле уеннар әйләнә – тирә чынбарлыкның күренешләрен, өлкәннәрнең тормышын һәм эшчәнлеген чагылдыра. Шуңа күрә, авыл җирлегендә яшәүче өлкәннәрнең хезмәтен чагылдырган “Терлекчелек” сюжетлы-рольле уены уйнау мөһимлеге туды. Баланың уен процессында бер – берсенә карата мөнәсәбәте, иркен аралашуы, гамәлләрендә иреклелек күзәтелә. Уенда баланың иҗади мөмкинлекләре киңәя, фантазияләре байый, төрле образга кереп, рольләрне оста башкара ала. Төрле тормыш ситуацияләрен уйнап, балалар килеп туган каршылыкларны җиңәргә өйрәнә, дуслык атмосферасы тудыра.

Уенның максаты: Балаларның практик эшчәнлегенә нигезләнеп, танып белү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль активлыкларын һәм иҗади фантазияләрен баету, тырышлык, өлгерлек, җитезлек, чисталык күрсәткече булган сыер савучыларга карата уңай эмоциональ караш тәрбияләү, аларга ошарга тырышу теләге уяту.

Уенның бурычлары: - социаль чынбарлык күренешләре белән танышу аша, сюжетлы рольле уен эчтәлеген баету;
-йорт хайваннары турында күзаллауларын һәм белемнәрен үстерү, “терлекчелек” сүзенең мәгнәсен төшендерү;
- бәйләнешле сөйләм үстерү, сүзлек запасын киңәйтү;
- танып белү активлыгын үстерү, тәҗрибәләренә таянып, әйрәнә – тирә турында күзаллауларын тулыландыру;
-уенны мөстәкыйль оештыру күнекмәләрен ныгыту;
- йорт хайваннарына һәм хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.

Уенда катнашучылар: балалар, тәрбиячеләр, ата – аналар, социаль партнерлар.

Җиһазлар: терлекчелек комплексы итеп эшләнгән ширма, савым аппараты, ноутбук, сыер савучы, мал табибы киемнәре, укол, дарулар, сөт үтү юлы итеп эшләнгән трубалар, перчаткалар, сыер макеты, су һәм азык өчен улаклар, терлек азыклары, эш кораллары: көрәкләр, тырмалар, сәнәкләр, чиләкләр, арбалы трактор, капчыклар, сөт ташу автомобиле.

Уенга алдан әзерлек эшләре: Авылыбызның сөтчелек комплексына сәяхәткә бару, авылның алдынгы сыер савучысы Хәйретдинова Нәкыя Нургазиз кызы белән очрашу, төрле кызыклы темаларга әңгәмәләр үткәрү: “Сыерларның файдасы”, “Сөт - иң витаминлы азык”, “Көтүче һәм көтү” хәрәкәтле уенын уйнау, авылыбызның КФК “Исмагилов” сөтчелек заводына сәяхәт, “Сыер” җырын өйрәнү (Ә. Ерикәй сүзләре, М. Мозаффаров көе)

Уенның барышы: Балалар, мин сезгә табышмак әйтәм, сез җавап бирерсез.

Аллы-гөлле чәчәкләрне,
Кетер - кетер ашый ул.
Шуннан ап-ак сөт ясап,
Көн дә безгә ташый ул. (Сыер). Бу табышмакның җавабы сыер.

Сез сыер белән бәйле нинди һөнәр ияләрен беләсез? (балалар җавабы) Әйе. Мин сезгә “Терлекчелек комплексы” нда уенын уйнарга тәкъдим итәм. Кемнәр эшли терлекчелек комплексында? Ферма мөдире, тракторчы, сыер савучы, терлекче, сакта торучы, мал табибы. Кем сыер савучы була? Сыер савучы сыерлардан сөт савып ала, сыер имиләрен юа, сөтне чиләкләргә тутыра. Ул – Самирә. Ә кемнең тракторчы буласы килә? Ул сыер тизәкләрен эттерә, сыерларга печән алып килә, силос, сенаж ташый. Ул - Сөләйман булыр. Ә кем терлекче булыр? Ул сыер тизәкләрен чистарта, сыерларга печән сала, силос, сенаж тарата. Ул - Зилә булыр. Ә кемнең мал табибы буласы килә? Ул авырган хайваннарны дәвалый. Ул - Айсылу булыр. Кемнең сөт ташучы буласы килә? Ул сөтне комплекстан сөт автомобиленә тутырып, сөт җыю пунктына илтеп тапшыра. Ул - Глеб булыр. Сакта торучы - Ильяс, ул терлекчелек комплексын тәртиптә тота, саклый. Мәйсәрә - терлекчелек комплексы җитәкчесе, бар эшчеләргә әмер бирә, күзәтә, эшчеләрне билгели.

Уен ситуацияләре: “Сөт саву вакыты”
”Сыерлар җәйләүдә”
“Терлекчелектә үлчәү көне”
”Фермада бер көн”
”Мал табибы килде”
”Терлекчелек комплексын җыештыру”
”Транспортир, савым аппараты белән танышу”.

Уенның тасвирламасы: “Терлекчелек” сюжетлы уенында балалар авыл хуҗалыгы һәм аның белән бәйле булган элеккеге һәм заманча һөнәр ияләре турында белемнәрен тирәнәйтәләр. Балаларның үз әти – әниләре, дәү әти - дәү әниләре һөнәрләренә карата кызыксыну арта. Уен тематикасын чагылдырган модуль балаларның күзаллавын, фантазияләрен, сүзлек запасын, диалогик, монологик сөйләмнәрен баета. Уен атрибутларының ачыклыгы, тулылыгы, матурлыгы балаларда төрле тормыш ситуацияләрен уйнау теләген үстерә.

Сюжет линиясен төрлеләндерү аша, балаларның иҗади мөмкинлеге ачыла. “Мал табибы килде”, “Сөт саву вакыты”, “Фермада бер көн”, ситуацияләрен кызлар да, малайлар да үзара иркен аралашып, дус – тату уйныйлар. Бирелгән модуль төрле уеннарны үз эченә ала, һөнәр ияләре белән якыннан танышырга ярдәм итә.

Көтелгән нәтиҗәләр: Сюжетлы - рольле уенга балаларны, ата – аналарны җәлеп итә алдык. Балалар уен аша, төрле һөнәр ияләре һәм аларның эшчәнлекләре турында белемнәрен ныгыттылар. Шулай ук, балалар done бербөтен булып, иптәшләренең фикерләрен тыңлап, дустанә мөнәсәбәт саклап, уйнау тәҗрибәсе тупладылар. Уен сюжетларын уйлап чыгарып, балаларның фантазияләре, диалогик сөйләмнәре, күзаллаулары, сүзлек байлыклары үсә.

## Кушымта №3

**“Тавык, үрдәк һәм әтәч” әкияте**

(Уртанчылар һәм зурлар төркеме балалары өчен)

Катнашкан курчаклар: тавык, әтәч, ике чеби, үрдәк.

Ширмада болын күренеше. Сул яктан тавык чыга, җирне тырный, җим эзли. Уң яктан үрдәк йөзеп килә. Яр кырыена чыга, кагына.

**Үрдәк.** (тавыкка). Бак – бак – бак, юкка гына азык эзлисең. Үлән арасында да, ермакта да бернәрсә юк.

**Тавык.** (борчылып). Чебиләремә нәрсә ашатыйм? Аларның тамаклары ач.

**Үрдәк**. Минем бибиләрем дә ач.

**Тавык.** Әйдә алайса җим эзлик.(Әтәч килеп керә.) Менә әтәчкәй килде. Ул безгә булышыр.

**Әтәч** (эре генә тавык белән үрдәк янында атлап йөри).

Кикрикүк, кикрикүк,
Минем әле тамак тук.

**Тавык** (әтәчкә). Әтәчкәем тауга менеп төш, җим эзләп.
Чебиләремне ашатырга кирәк.

**Әтәч**. (эре генә). Нәрсә? Миңа тауга менәргә?Аякларымны буярга? Юк! Менмим!

**Үрдәк** (ялкауланып). Бак – бак – бак, андый биек тауга менәргә көч кирәк.

**Тавык**. Ярар, мин азык эзләп төшим әле. (Тауга менә, җирне тырный, як – ягына карана. Үрдәк белән әтәч тавыкка карап торалар). Кыт – кыт – кыт, бөртек таптым. (Таудан төшә). Карагыз, нинди бөртек таптым. Кайсыгыз миңа бөртекне утыртырга ярдәм итә?

**Үрдәк.** Мин генә түгел.

**Әтәч**. Мин дә түгел.

**Тавык.** Димәк, мин.
Чебиләрем сез кайда?
Килегезче яныма.

**Чебиләр** (тавык янына чыгалар).

Ни телисең, чип – чип – чип?
Без эшлибез бик тиз бит.

**Тавык** (җирне тырный).
Мин чәчәм җиргә бөртек.
Кызганмый бер дә көчем.

**Чебиләр**. Без аңа су сибәрбез.
Ул тизрәк үссен өчен.

**Тавык бөртек утырта, чебиләр су сипкечтән су сибәләр, акрынлап биек башаклар үсеп чыга.**

**Чебиләр**. Бөртек башакка әйлән,
Бездә булыр зур бәйрәм!

**Тавык** (исе китеп). Кыт – кыт – кыт, монда чын икмәк басуы булган!

**Үрдәк**. Бак – бак – бак, минем бибиләремә дә җитәр.

**Әтәч.** Кечкенә чебиләргә дә!

**Тавык**. Кем ашлыкны җыяр?

**Үрдәк.** Мин түгел.

**Әтәч** (эреләнеп). Мин дә түгел! (Тавыкка арты белән борылып баса).

**Тавык** (чебиләренә).
Чебиләрем килегез,
Кулга алабыз урак.
Икмәкне вакытында,
Җыеп алырга кирәк.

**Урак белән икмәк җыю күренеше. Тавык алдан, чебиләре аның артыннан баралар. Тавык кибән ясый.**

**Тавык.** Без тырышып эшләдек.
Ялкаулыкка бирешмәдек.
Кем уңышны тегермәнгә алып бара?

**Үрдәк**. Мин түгел!

**Әтәч.** Мин дә түгел.

**Тавык.** Ярар үзем барырмын.

**Чебиләр** (сөенешеп). Без дә, без дә!

**Тавык җилкәсенә капчык асып тегермәнгә бара. Хәрәкәт эшчәнлеген күрсәтү өчен чәчәк, агач, куак аларга каршы хәрәкәтләнәләр.Тегермән күренә, тавык белән чебиләр туктала лар.**

**Тавык.** Исәнме дустым тегермән,
Синең янга килдем мин.
Зинһар өчен ашлыктан,
Безгә он ясап бир син.

**Тегермән әйләнә башлый, тавык белән чебиләр тегермән әйләнешенә башларын әйләндереп торалар. Тегермәннән бер капчык он төшә.**

**Тавык** (капчыкка иелеп). Нинди ак он! Хөрмәтле тегермән, эшең өчен зур рәхмәт.

**Тегермән**. Мин тегермән,
Эшләргә бик яратам.
Ярдәм сорап килгәннәргә,
Булышмыйча калмам.

**Тавык белән чебиләр капчыкны күтәреп кайталар. Каршыларына үрдәк белән әтәч очрыйлар.**
**Тавык** (сөенеп). Карагыз әле, нинди ак он алып кайттык. Кем тәмле ипи пешерә?
**Үрдәк.** Мин түгел.
**Әтәч.** Мин дә түгел.
**Йөгереп качып китәләр.**
**Тавык.** Ярар, үзем пешерәм. (Алъяпкычын киеп куя.)

Алъяпкычымны ябам,
Җиңнәремне сызганам.
Мин хәзер ипи салам.
Әйдә әле килегез,
Сез дә карап торыгыз.

**Чебиләр әниләре - тавык эшләгәнне күзәтәләр. Тавык ипине мичкә куя. Үрдәк белән тавык чыгалар.**
**Үрдәк**. Эшләр ничек бара?
**Әтәч**. Ипиең көеп китмәсен.
**Тавык**. Борчылма Әтәчкәй, ипи күптән әзер инде, өстәлгә утырырга да вакыт җитте, тәмам арыдым.

Туктагыз әле, туктагыз!
Ипине кем ашарга тиеш? дип
Нигә сез сорамыйсыз?
Әллә инде бу турыда,
Сез бер дә уйламыйсыз.

**Әтәч.** Әлбәттә, мин.
**Үрдәк**. Ничек инде миңа булмасын!
**Тавык**. Ипи сезгә түгел, миңа һәм минем чебиләремә тиеш, чөнки чебиләрем миңа булыштылар.

Чебиләрем килегез,
Ипекәйне күрегез.
Табын түренә утырып,
Сез дә авыз итегез.

**Чебиләр**. Безнең әнидән дә яхшырак әни җир йөзендә юк, юк, юк! Кем эшләми, шул ашамый!
**Тавык.** Чебиләрем арттан калмагыз! (Музыка астында кереп китәләр.)

Искәртмә: Тау картоннан эшләнә һәм яшел төскә буяла. Тегермән картоннан киселә, әйләнеп торучы канатлар белән эшләнә. Ипи папье – маше яки мамыктан ясала. **Тәмам.**

## Кирләмән мажаралары.

(Уртанчылар һәм зурлар төркеме балалары өчен)

**Катнашкан курчаклар:** Мәликә, Акбай, Мырау.
**Мәликә** (чыга һәм уртада туктала, киреләнә, битен куллары белән каплый).

Кулларымны юмыйм мин,
Ашарга да теләмим.

Көне буе елыйм мин,
Беркемне дә тыңламыйм.

**Акбай белән Мырау читтән Мәликәне карап торалар, кызга карап акрын гына сөйләшәләр.**

**Акбай**. Безнең Мәликә белән нәрсә булды икән?Ул елый, кычкыра, бер нәрсә эшлисе килми.

**Мырау**. Без аның белән сөйләшик, юатыйк үзен. (Мәликә янына киләләр).

**Акбай**. Бүген урамда нинди рәхәт, әйдә йөреп керик.

**Мәликә.** Мин матур көн булуын теләмим, яңгыр яусын. (елый).

**Мырау**. Яңгыр яуса, син юешләнерсең бит.

**Мәликә**. Юешләнсә ни! (елый)

**Акбай.** Ә бәлки синең ашыйсың киләдер, Мин сиңа...

**Мәликә**. (сүзен бүлә). Берни дә теләмим, кәнфит тә, кәтлит тә, чәй дә, сөт тә.(Елый)

**Мырау.** Туңдырма да ашыйсың килмиме?

**Мәликә.** Туңдырма да, пирожный да! (Елый)

**Акбай**. Ә бәлки сиңа салкындыр? Яулык алып килимме?

**Мәликә.** Миңа җылы да, салкын да түгел! Миңа берни кирәк түгел! (Елый)

**Акбай.** Ә ни өчен син елыйсың да, елыйсың?

**Мәликә**. Нигә мине борчыйсыз?
Елыйсың дип сорыйсыз.
Киреләнәм күпме кирәк,
Миндә бары шул теләк.

**Акбай.** Ә бәлки син авырыйсыңдыр? А – а – а диген әле!

**Мәликә**. Бә – ә – ә!

**Мырау**. Сула әле!

**Мәликә**. Үзегез сулагыз.

**Акбай**. Хәзер без сине тыңлап карарбыз (Төрле яклап Мәликәне колаклары белән тыңлыйлар)

**Мырау**. Булган бу.

**Акбай.** Ай – яй – яй.

**Мәликә**. Нәрсә булган соң миңа?

**Мырау.** Булган инде менә.

**Мәликә**. Нәрсә турында сөйлисез сез?

**Акбай белән Мырау читкә китеп сөйләшәләр.**

**Акбай.** Ярар Мәликә, булса булсын, сер итеп кенә әйтәбез сиңа.

**Мырау**. Тик берәүгә дә сөйләмә.

**Мәликә**. Берәүгә дә әйтмәм, нәрсә булганын әйтегез генә.

**Акбай**. Син Кирлемәнне йоткансың!

**Мырау**. Ул монда очып йөргән дә, син елаган вакытта авызыңа очып кергән.

**Мәликә**. Мин Кирлемәнне йоткан? Ә нинди соң ул?

**Акбай.** Ул бик усал һәм саран,
Юынмаган куркыныч хайван.
Елаганны саклап торган да,
Синең эчеңә кереп утырган.

**Мырау**. (Мәликәнең эчен күрсәтә.) Монда ул, монда!

Якында гына!
Исеме аның – Кирлемән.

**Акбай.** Ул синең эчеңә кереп утырган һәм син үзең Кирлемәнгә әйләнгәнсең!

**Мәликә**. Минем Кирлемән буласым килми.

**Акбай.** Алай булса кычкырып әйт: “Минем Кирлемән буласым килми. Мин киреләкләр башка эшләмәм. Кирлемән, чыгып кит минем эчемнән!”

**Мәликә.** Кирлемән буласым килми! Кирлемән чыгып кит!

**Акбай һәм Мырау**. Очып чыкты! Әнә ул, әнә ул, куыгыз аны! (Йөгерәләр, тәпиләре белән селкиләр)

**Мәликә.** Ә хәзер кая очып китте Кирлемән?

**Акбай**. Ул, авызын ачып елап, киреләнеп утыручы балаларны эзли. Аларның авызларына очып керә дә, балалар Кирлемәнгә әйләнә.

**Мәликә**. Мин башка еламаячакмын.

**Бергә**: Нәни дуслар сезгә әйтәбез:
Тәртипле, акыллы булыгыз!
Ә Кирлемәнне усалны,
Тизрәк еракка куыгыз! Тәмам.

**“Кызыл кикрик белән Йомшаккай маҗаралары” әкияте**
**(Уртанчылар һәм зурлар төркеме балалары өчен)**

**Катнашучы курчаклар: Ләйлә, этәч Кызыл Кикрик, мәче Йомшаккай.**

**Ширманың уң ягында йорт, сул якта урман.**

**Ләйлә.** (йорттан чыга) Кызыл кикрик, кил әле яныма!

**Кызыл кикрик**. Кикрикүк. Мин монда. Хәерле иртә!

**Ләйлә.** Әтәчкәй, син ни өчен иртә белән җырламадың? Ни өчен мине йокыдан уятмадың? Миңа урманга җиләккә барырга кирәк иде.

**Әтәч.** Мине гел җырлап яшәү туйдырды. Мин сине башка йокыдан уятмаячакмын (читкә китә)

**Ләйлә.** Пес – пес – пес, Йомшаккай, кил әле яныма.

**Йомшаккай. (**чыга) Мяу – мяу. Мин монда. Хәерле иртә!

**Ләйлә.** Ни өчен син Йомшаккай, бүген тычкан тотмадың? Алар өстәл өстенә менгәннәр, ипине, майны ашаганнар.

**Йомшаккай.** Минем төнлә белән йоклыйсым килә, тычкан тотасым килми. (читкә китә)

**Ләйлә**. Ярар, ничек телисез. (йортка кереп китә).

**Кызыл кикрик.** (мәче янына килә) Әйдә Йомшаккай, Ләйләдән качып, урманга китәбез. Шунда яшәрбез, туйганчы йокларбыз.

**Йомшаккай.** Әйдә качабыз. Ә ашарыбызга ризыкны чиратлашып табарбыз. Бер көнне мин, икенче көнне син. Яхшымы?

**Кызыл Кикрик**. Бик яхшы, әйдә, юл хәстәрен күрергә кирәк.

**Йомшаккай**. Ашыгыйк, тизрәк, тизрәк! (йөгереп чыгып китәләр)

**Урман. Алгы планда Кызыл кикрик.**

**Кызыл кикрик.** Ничек рәхәт, эш кушучы да юк. Телисең икән йоклыйсың, телисең икән ашыйсың.
**Йомшаккай.** (әтәч янына килә) Тор, Кызыл кикрик. Мин көн буе урманда ауда йөреп тә, бары бер генә тычкан тоттым. Аны уртага бүлеп ашарбыз.
**Кызыл кикрик.** Син нәрсә, Йомшаккай? Мин бит тычкан ашамыйм. Миңа ярма кирәк. Иртәгә үзем барачакмын ризык эзләргә. Нигәдер туңып киттем дустым. Тамагым ач булгангадыр инде.
**Йомшаккай.** Киче дә бик салкын. Авырып китә күрмә, сине дәваларга Ләйлә дә юк бит. Әйдә учак ягыйк, авылда яшәгәндә, мин хуҗаларның учак якканнарын күргәнем бар иде.(шырпы кабызып учак яга)
**Кызыл кикрик.** Рәхмәт Йомшаккай, җылындым, йокым килә башлады.(киерелә, йоклый)
**Мәче белән әтәч йокыга тала. Учактагы ут якындагы агачларга үрмәли.**
**Йомшаккай.** (киерелә, йокысыннан уяна) Каяндыр төтен исе килә. Кызыл кикрик тор әле тизрәк.
**Кызыл кикрик.** Нигә вакытсыз уятасың? Йокым туймады бит.
**Йомшаккай.** Урман яна башлаган. Нишләргә инде хәзер? Барсына да без гаепле. Тизрәк ярдәм чакырырга кирәк.
**Кызыл кикрик.** Мин Ләйлә янына авылга очыйм, ул нәрсә булса да уйлап табар, ә син утны сүндерә тор.

**Ләйләнең йорты күренеше.**

**Кызыл кикрик.** (йорт янына килә) Ләйләкәй, урамга чык тизрәк.
**Ләйлә.** (тәрәзәдән) Кем чакыра мине? Ә, бу син икән Кызыл кикрик. (йорттан чыга) Кайда югалып йөрисең? Йомшаккай кайда?
**Кызыл кикрик.** Ләйлә, безгә синең ярдәмең кирәк. Урманга ут капты, тиз тотып сүндермәсәк, агачлар янып бетәчәк.
**Ләйлә.** Әйдә тизрәк, ашыгырга кирәк. (Ләйлә белән Кызыл кикрик чиләкләрен алып йөгерәләр)
**Урман күренеше. Ләйлә, Кызыл кикрик, Йомшаккай агачларга чиләк белән су сибәләр. Утны туктаткач, хәлдән таеп, ял итәргә утыралар.**
**Йомшаккай.** Безнең үзебезчә генә яшәргә теләвебез нәтиҗәсендә нинди бәла килеп чыкты.Гафу итегез безне барыгыз да.
**Кызыл кикрик.** Үз гаебебезне таныйбыз, яз җитүгә яшь агачлар утыртырбыз.
**Ләйлә.** Бу юлы гафу итәбез. Әйдәгез хәзер мин сезне ашатыйм. Сиңа, Кызыл кикрик тәмле ярма, ә сиңа, Йомшаккай җылы сөт бирим.

**Барысы да йортка кереп китәләр. Тәмам.**

## Балалар бакчасында театральләшкән тамаша “Көзге бакчада”
## (Уртанчылар һәм зурлар төркеме балалары өчен)

**Катнашучылар:**балалар, ата – аналар.
**Алып баручы.** Борын – борын заманда Балык – бистәсе районы, Олы Елга авылында яшәгән ди әби белән бабай. Аларның бик матур кызлары бар

икән.  Асраганнар мәче белән эт, алар булган бик тә дус. Беркөн бабай бакчада яшелчә утыртырга уйлаган.

**Бабай. –** Бакчама яшелчә утыртырга кирәк**.** (өй каршындагы урындыкка утыра)

Лаеклы ялда мин хәзер,
Көн буе тик ятам.
Яшелчә утыртыйм әле,
Эш булыр ичмасам.

**Алып баручы.** Бабай бакчаны казыган, җирне тырмалаган һәм яшелчә орлыклары утырткан. (бабай казыган, тырмалаган, орлык утырткан хәрәкәтләр башкара)

**Бабай.** Эшләп арыдым, азрак ял итеп алыйм. (бабай өйгә кереп китә)

**Күңелле көй уйный, әтәч кычкыра, бабай өйдән чыга.**

**Бабай.** Кызым яшелчәгә су сип әле, чүпләрен дә утарсың.

**Кыз.** Хәзер бабакаем. (йөгереп чыга)

Яшелчәгә су сибәм,
Ул тизрәк үссен өчен.
Чүпләрен дә утармын,
Кызганмый бер дә көчем**. (**су сибү, чүп утау хәрәкәтләре ясый)

**Бабай.** Рәхмәт кызым, тырыштың**.**

**Бакчага кошлар очып төшләр, очып йөриләр.**

**Кош.** Бигрәк тамагым ачты,
Бакчага төшим әле.
Бабакай чәчкән орлыкны,
Мин авыз итим әле.(кошлар орлыкны чүпләгән хәрәкәтләр ясыйлар)

**Бабай. Акбай, бакчага кошлар төшкән, кошларны куарга кирәк.**

**Акбай**.(өреп чыга) Һау – һау – һау
Мин бик уяу.
Кошлар монда килмәгез,
Яшелчәгә тимәгез.(кошларны куа, кереп китә)

**Алып баручы.** Менә алтын көз дә килеп җиткән. Бакчада яшелчәләр өлгергән.

**Тезелеп баскан балалар яшелчәләр турында шигырьләр сөйлиләр.**

**Кирилл.** Мин бәрәңге, бәрәңге,
Менә мине күр әле.
Сап – сарыдыр төсем,
Ничек тырышып үстем.

**Зәмирә**. Карагыз әле бер генә,
Менә миңа кабакка.
Турап куйсагыз сыймыйм,
Хәтта иң зур табакка.

**Ранил.** Яшелчәләр арасында,
Мин дә үсәм бит туган.
Суык тимәсен дисәң,
Күбрәк утырт син суган.

**Чулпан.** Мин – помидор - светофор,
Мин пештем кызарып.
Туктыйлар да сокланалар,
Китә алмыйлар кузгалып.
**Ислам.** Яшелчәләр арасында,
Иң тәмлесе – мин кыяр.
Җәй буена ашап туйгач,
Калганын тозлап куяр.
**Сөмбел**. Кат – кат тунлы, карыш буйлы,
Мине генә карагыз.
Барысыннан да матур,
Мин кәбестә апагыз.
**Кәрим.** Мин чөгендер кешеләргә ,
Бик күп файда китерәм.
Кешедәге авыруларны,
Вакытында бетерәм.
**Мөслимә** Менә мине күрегез
Кишер генә димәгез.
Мине ашаган кешенең,
Тешләре нык белегез.
**Азалия.** Мин шалкан, шалкан, шалкан,
Яңгыр сулары эчтем.
Кояш нурында үстем,
Зур булып үстем.
**Балалар көз кызы Сөмбелә белән "Көз, көз әйт әле" җырлы – биюле уенын башкаралар.**

**Алып баручы.** Беркөнне бабай яшелчәләрне карарга дип бакчага чыккан, ни күзе белән күрсен шалкан зур булып үскән. Бабай шалканны тартырга тотынган.(бабай йорттан чыга, шалканны әйләнеп чыга, тартып карый, тарта алмый)

**Бабай.** Ай – яй шалкан зур үскән,
Мине дә узып киткән.
Көчем җитми тартырга,
Кирәк әбине чакырырга.

Әби, кил әле шалканны тартырга булыш әле.(Йорттан әби чыга, шалканны күреп шаккаткан хәрәкәтләр ясый. Бабай белән әби шалканны тарталар)

**Әби.**Бабакайның хезмәте,
Бер дә бушка китмәгән.
Чыгарып булмас тартып,
Кызыма дәшим әле.

Кызым, кил әле, шалканны тартырга булыш әле.

**Кыз.** Киләм әбием.(шалканны әйләнеп чыга)
Шалканны үстерергә,
Мин дә ярдәм иттем.
Су сиптем, чүп утадым,

Бер дә тик ятмадым.(бабай, әби, кыз шалканны тарталар, тартып чыгара алмыйлар)

**Кыз**. Акбай кил әле, шалканны тартырга булыш әле.(Акбай чыга, шалканны тарталар, тартып чыгара алмыйлар)

**Акбай.** Бабай чәчкән орлыкны,
Кошлардан мин сакладым.
Бер дә йокы күрмәдем.
Ә шалканы, шалканы,
Тартып чыгарып булмады.

Мырау кил әле, шалканны тартырга булыш әле. (Мырау чыга, шалканны тарталар, тартып чыгара алмыйлар)

**Мырау.** Мин Мырауҗан-
Булам нәфис затлардан.
Мондый зур шалканны,
Һич тә тарта алмам.

Чи – чи кил әле, шалканны тартырга булыш әле. (Чи – чи чыга, шалканны тарталар)

**Алып баручы.** Бабай шалканга, әби бабайга, кыз әбигә, Акбай кызга, Мырау Акбайга, Чи – Чи Мырауга тотынып шалканны тарталар икән, тарталар икән, тартып та чыгарганнар.

**Чи – Чи.** Барыбыз да җыелдык,
Тырышып эшләп алдык.
Күмәк көч белән шалканны,
Җирдән тартып чыгардык.

**“Дустым бар” җырын түгәрәктә җырлап әйләнәләр. Тәмам.**

## Кушымта №4

“Кышкы табигать” темасына уртанчы яшьтәге балалар өчен квест - бердәм эшчәнлек.

**Тема:** Кышкы табигать.

**Максат:** Кышкы табигать, кышлаучы кошлар турында белем бирү.

**Тәрбия бурычы:** Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфатларын тәрбияләү. Кошларга карата сак караш, шәфкатьлелек, миһербанлык хисләре тудыру.

**Үстерү бурычы:** Балаларның күзаллавын, диалогик, монологик, бәйләнешле сөйләм күнекмәләрен формалаштыру. Логик фикер йөртү, гади нәтиҗәләр ясау сәләтләрен үстерү.

**Белем бирү бурычы**: Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү. Безнең якларда яшәүче кышлаучы кошларның гәүдә төзелешен, туклану үзлекләрен, исемнәрен ныгыту.

**Белем бирү өлкәсе**: танып белү.

**Интегральләшкән белем бирү өлкәләре**: танып белү, матур әдәбият, математика, иҗат, физкультура, социальләштерү

**Методик алымнар:** күрсәтмәлелек, сүзле, практик, уен, дидактик уеннар, сораулар,
әдәби сүз, сөенеч мизгеле.
**Сүзлек эше**: җимлек, кышлаучы кошлар.
Алдан эшләнгән эшләр: рәсемнәр карау, әңгәмәләр үткәрү, матур әдәбият әсәрләрен уку.
**Җиһазлау:** рәсемнәр, уенчык кош - перчатка, ширма, мультимедия – проектор, җимлек ясау өчен атрибутлар,

Эшчәнлек төзелеше:

1. Эмоциональ халәт тудыру, кереш мизгеле.
2. Сөенеч мизгеле.
3. Дидактик уен.”Сурәтне таны”
4. Уен. Лабиринт.
5. Пазл төзү уены.
6. Су, боз белән тәҗрибә.
7. Җимлек ясау остаханәсе. Кышлаучы кошлар турында әңгәмә.
8. Дидактик уен “Кошны өлештән җый”
9. Кошларны чакыру.
10.Хәрәкәтле уен. “Без- кошлар”
11. Йомгаклау.

## Эшчәнлек барышы.

Исәнмесез, хәерле көн, балалар! Минем яныма якынрак килегез, бер-беребезнең кулларыбыздан тотынышыйк, бер-беребезгә карап елмаешыйк, үзебезнең күңел җылыбызны бүләк итик. Кышкы салкын көннәрдә җылылык безгә бик кирәк. Менә ничек рәхәт булып китте! (1 слайд)
Тәрбияче. Мин ниндидер тавыш ишетәм.
**Тәрбияче курчак - перчатка - чыпчык уенчыгы белән әңгәмә үткәрә**.
**Тәрбияче.** Исәнме чыпчык дускай. (2 слайд )
Чыпчык. Исәнмесез балалар . Хәерле көн. Минем дусларымны усал кар патшабикәсе сихерләде.
**Тәрбияче.** Тыңлыйк әле балалар, Кар патшабикәсенең безгә әйтер сүзе бар.(3 слайд +видео)

**Экранда патшабикә сөйли**.

Исәнмесез. Минем патшалыгымдагы урманнарда бик күп хайваннар, кошлар яши. Мин тынычлык яратам. Ләкин кышлаучы кошлар минем тынычлыгымны бозып, көн дә чыркылдашалар, каядыр очалар, колагымны тондыралар. Көзгемне дә ватканнар. Түземлегем бетте. Мин кышлаучы кошларны сихерләдем. Бары тик батыр, тырыш балалар гына аларны коткара ала.
**Тәрбияче.** Ай – ай балалар кошлар белән нәрсә булган икән бит. Алар бездән ярдәм көтәләр. Сез шундый батырлар, тырышлар, ярдәмчелләр. Сез нәрсә тәкъдим итәрсез. (балалар фикере тыңланыла, ярдәм итәбез)
**Тәрбияче.** Юлга кузгалганчы урамда үз – үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшереп үтик. (4 Слайд - кагыйдәләр)

- **Тәрбияче.** Әйдәгез юлга кузгалдык. (перчатка – чыпчыкны кулына кия)Хәзер кыш ел фасылы булганга юллар нәрсә белән капланган? Кышкы юллар кар белән капланган. Аякларыбызга нәрсә кисәк юлыбыз җиңеләер? (5 слайд - чаңгы)
**Тәрбияче.** Кышкы урман аланына килеп җиттек. Нәрсә күрәсез аланда? (бар җирне кар каплаган, салкын көнне кар бөртекләре ялтырый. Урман һавасын сулау. (6 слайд)
**Тәрбияче. Монда безнең өчен ниндидер бирем бар.**
**Бирем.** 1 – 5 кадәр саннар арасында булган нокталарны тоташтырып, сурәтне таныргa. (1 бала ясый, карга рәсеме чыга).
**Тәрбияче** .Балалар, карга ничек кычкыра ? Әйе, “кар”,”кар”ди. Кабатлагыз, бергәләп.Тәрбияче балага карга курчак - перчаткасын бирә. (7 – 8 слайд)
**Тәрбияче.** Кар патшабикәсенең көзгесенең беренче өлешен таптык ( беркетеп куялар)
**Тәрбияче**. Юлны дәвам итәбез. Балалар карагыз, бозда кеше аяк эзләре калган.Аяк эзләренә басып вак адымнар белән барабыз. Эзләр безне киләсе биремгә илтер. (9 слайд. экран янына баралар)
**Тәрбияче.** Экранда **Лабиринт уены** сурәтләнгән. Аны дөрес итеп үтеп, нинди кошны коткарырбыз икән?(10 слайд). Бер бала күрсәткеч таягы белән күрсәтеп бара**, саескан** кошын таба). Саескан башка кошлардан кайсы ягы белән аерыла? (койрыгы озын)
Тәрбияче бирем үтәүче балага тәрбияче саескан перчатка – курчагын кидерә.(икенче көзге өлешен куялар)
**Тәрбияче.** Юлда барганда яхшы иптәш барыбызга бик кирәк.
**Тәрбияче.** 3 нче биремне үтәр өчен безгә биек кар көртләре комачаулый. Аякларны югары күтәреп юлыбызны дәвам итик. (11 слайд.).
**Тәрбияче**. Балалар сезгә пазлны җыярга кирәк.. ( кыш сурәте). Икенче ягында карабүрек кош рәсеме сурәтләнгән. Дусларым без пазлны җыеп нинди кошка ярдәм иттек.
( 12 слайд). Балага тәрбияче карабүрек перчатка – курчагын кидерә, өченче көзге өлешен бирә.
**Тәрбияче.** 4 нче биремне үтәр өчен шигырьне кабатлап, марш атлап барырга кирәк.
Бер, ике, өч
Безнең кулда көч.
Бер, ике, өч.
Безнең ил тыныч**. (13 слайд)**
**-**Дусларым без сезнең белән кайда яшибез? (Татарстанда). Әйе балалар, Татарстан халкы күп еллар дәвамында дус, тату яши. Кайсы кышлаучы кошны тынычлык символы итеп куялар.(Күгәрчен кошын). Балалар карагыз күгәрчен нинди бәлагә юлыккан? Кар патшабикәсе аны бозга туңдырган. Боз нинди?(каты, салкын, үтә күренмәле).Ә ничек аны коткара алабыз? (14 слайд.Тәҗрибә)
**Тәҗрибә. Су һәм боз кисәкләре.** Ике савыт тора. Берсендә җылы су, икенчесендә боз. Тәрбияче. Димәк: **җылы су бозны тиз эретә**. Дөрес нәтиҗә

чыгарып, күгәрченне коткардык. Балага тәрбияче күгәрчен - перчатка – курчагын кидерә, дүртенче көзге өлешен бирә. (15 слайд)

**Тәрбияче.** Карагыз эле көчле җил, давыл чыкты. Әйдәгез урманга таба барыйк, анда агачлар безне җилдән саклар. Балалар бер беребезгә якын итеп парлашып басып, җилне җиңеп алга барабыз. (16 слайд). Җил тавышы ишетелә.
Чыршы төбендә җимлекләр күрәләр. (17 слайд.).
**Тәрбияче.** Патшабикәнен ачуы зур булган. Хәтта җимлекләргә дә зыян килгән. Балалар кошларның зурлыгына карап сайлап алыгыз һәм эшкә керешик.
1. Таяк нәрсә өчен кирәк( басып ашау өчен - беркетәләр)
2. Җеп нәрсә өчен кирәк?( агачка элеп куяр өчен). Кошларыгызда булган төсләргә карап җепне сайлап аласыз.
**Тәрбияче.** Җимлек әзер. Җимлеккә нәрсәләр салабыз. (конбагыш, тары ярмасы, май.
**Тәрбияче.** Сезнең алдыгызда төрле җимнәр салынган савытлар. Күңелегезгә охшаган җимне сайлап, җимлеккә салабыз. ( һәрберсенең савытыннан песнәк кошының бер өлеше чыга. Балалар **“Өлештән кошны җыялар”.** 18 слайд. **(**Балага тәрбияче песнәк перчатка – курчагын кидерә, бишенче көзге өлешен бирә)
**Тәрбияче.** Кар патшабикәсенең көзгесе әзер, рәхмәт сезгә , бик тырыштыгыз. Ә хәзер күңел ачыйк.
**Тәрбияче.** Сезнең һәрберегезнең якын дусты бар, ә мин сезне җимлеккә чакырам. Үз исемен ишеткән кош җимгә килә.19 слайд
Килегез, кил кошкайлар,
Сез бит безнең дускайлар.
Җимлеккә сез куныгыз,
Көн дә кунак булыгыз.
**Песнәк, песнәк,** кил тизрәк
Җим сибәм сиңа әзрәк.
**Кызылтүшем** оялма,
Җим сибәмен бер оя.
**Күгәрченем** гөр-гөр-гөр,
Җим сиптем менә күр-күр.
**Саескан** ала канат,
Җим сибәм кабат – кабат.
**Карга, карга** әй карга
Дусларыннан син дә калма.
**Тәрбияче.** Барыбыз да җыелдык, ә хәзер сыйланабыз. 20 слайд.
Менә кошлар очып килде җимлеккә (очалар)
Әй сөенде алар анда җим күпкә (сикергәлиләр)
Әй чукыйлар алар җимне җимлектән (башлары белән чукыган хәрәкәт ясыйлар)
Сөенешеп тыпырдыйлар җимлектә. ( тыпырдыйлар).

**Кар патшабикәсе чыга**. Исәнмесез. Сез тагын, минем тынычлыгымны бозып чыркылдашасызмы? Хәзер мин сезне.
**Тәрбияче.** Тукта Кар патшабикәсе син безне ачуланма. Без кошларны коткарыр өчен бик күп тырыштык, синен тылсымлы көзгеңне төзәттек. Менә рәхим итеп ал.
**Кар патшабикәсе**. Сез төзәткән көзгедән карагач, күнелем йомшарды, гел яхшылыклар гына эшлисем килә башлады. Рәхмәт сезгә балалар. Сезгә бүләк итеп кечкенә көзгеләр алып килдем. Миңа үземнең кар патшалыгыма кайтсам да була.
**Тәрбияче:** Рәхмәт Кар патшабикәсе бүләкләреңөчен. Дусларым, татар халкында "Үзең нинди, көзгең шундый" – дигән мәкаль бар. Әгәр сез көзгегә елмаеп, яхшы күңел белән карасагыз, ул да сезгә шулай карар һәм сезнең һәрвакыт күңелегез яхшы булыр. Дусларым без бүген никадәр яхшылыклар эшләдек, никадәр белемнәребезне ныгыттык.

**-**Сез миңа бик ошадыгыз, мин дә сезнең белән дуслашырга өлгердем.

**-**Сез бүген белгәннәрегезне кемнәргә сөйләрсез? Тәмам.

## Кушымта №5

Артикуляция күнегүләренең *максаты* - авазларны дөрес әйтү өчен артикуляция аппараты органнарының аерым бер торышының тулы кыйммәткә ия булган хәрәкәтен тәэмин итү.

Артикуляция күнегүләрен үткәрүне оештыру.

1. Өлкәннәр алда торган күнегү турында уен алымнары белән сөйлиләр.
2. Өлкәннәр күнегүне эшләп күрсәтәләр.
3. Бала күнегүне эшли, өлкәннәр аны күз уңында тота.

Артикуляция күнегүләрен алып баручы кеше бала тарафыннан эшләнгән хәрәкәтләрнең сыйфатын: төгәллеген, салмаклыгын, башкаруның темпын, тотрыклылыгын, бер хәрәкәттән икенчесенә күчүен күзәтергә тиеш. Артикуляция күнегүләре симметрияле алып барылырга тиеш. Йөзнең уң ягына үткәрелгән күнегү эзлекле рәвештә сул як йөзгә дә эшләнелә.

4.Бала телнең дөрес торышын тапсын өчен, әйтик, өске иренне яласын өчен варенье яки шоколад, яки бала яраткан башка нәрсә буяп юнәлеш бирергә була. Күнегүләрне эшләтүгә иҗади якын килергә кирәк.

Күнегүләрнең башында балаларның артикуляция аппараты әгъзаларында киеренкелек сизелә. Алга таба киеренкелек югала, хәрәкәтләр иркен һәм координацияләнгән була башлый.

5. Балага "Телең хәзер ни эшли? Ә иреннәр? Телең хәзер кайда, өстәме әллә астамы?" – дигән сораулар белән юнәлеш бирергә кирәк.
6. Истә тотарга кирәк: һәр баланың яңаны үзләштерүдә үз темпы, үз мускул әзерлеге. Әгәр дә күнегүләр эшләүдә кыенлыклар туса, баланы ашыктырмагыз, битәрләмәгез.

Артикуляция моторикасын үстерү системасы күнегүләре статик күнегүләр белән бер рәттән сөйләм хәрәкәтләренең динамик координацияне үстерү юнәлешен дә үз эченә ала.

## ***Тәкъдим ителгән күнегүләр:***

***1. “Су үгезе”*** (Бегемот)

Авызны тыныч кына зур итеп ачарга һәм ябарга. Күнегүне 4-5 тапкыр кабатлыйбыз. Балага хәл алырга һәм ял итәргә вакыт бирәбез. Авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатлыйбыз.

***2. “Елмаю”***

Кысылган тешләр күренерлек итеп ирен почмакларын җәябез. Иреннәрне янә үз хәленә кайтарабыз. Балага хәл алырга һәм ял итәргә мөмкинлек бирәбез, авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатлыйбыз.

***3. “Фил борыны”*** (Хобот)

Үбәргә теләгән кебек иреннәрне алга торба итеп сузабыз, шул рәвешле 4-5 секунд тотабыз. Иреннәрне кире тыныч торышка кайтарабыз. Балага хәл алырга һәм ял итәргә вакыт бирәбез, авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатлыйбыз.

***4. “Әрлән баласы”***

Балага авызны япкан килеш яңакларны кабартырга тәкъдим ителә. Шул рәвешле 4-5 секунд тотканнан соң һавасын чыгара. Авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатлыйбыз.

***5. “Көрәк”***

Авызны киң итеп ачарга. Йомшак һәм тыныч телне аскы ирενгә куябыз. 3-4 секунд тоткарлагач, телне кире алабыз. Балага хәл җыярга һәм ял итәргә вакыт бирәбез. Авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатлыйбыз.

***6. “Песи баласы сөт ялый”***

Авызны киң итеп ачабыз, песи баласы сөт эчкән кебек телнең киң өлешен 4-5 тапкыр өскә хәрәкәт иттерәбез. Телне эчкә алабыз, авызны ябабыз. Авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне янәдән кабатлыйбыз.

***7. “Касә”***

Авызны киң итеп ачабыз, киң телне аскы иренгә куябыз, телне касә сыман итеп өскә каратып бөгәбез һәм салмак кына өске тешләргә күтәрәбез. Алга таба балага телне төшерергә, авызны ябарга, хәл алырга, авыз сыекчасын йотарга тәкъдим итәбез. Күнегүне 3-4 тапкыр кабатларга.

Кушымта №6

Бармак театры өчен курчак (чеби) әзерләү буенча мастер класс.

Кирәк булачак: сары, куе сары, кызыл, яшел төсле фетр,  сары, куе сары чигү җебе, энә, кайчы, шаблоннар, күзләр.



Шаблоннар ярдәмендә чебинең гәүдә – баш өлешен, кикриген, канатларын кисәбез.



Киселгән өлешләрне энә, җеп ярдәмендә тегеп чыгабыз. Клей ярдәмендә күзләрен, томшыгын, чирәмне ябыштырабыз.



Уенчык чебиебез әзер.



**Кушымта №7**

**Олы Елга авылының “Умырзая” балалар бакчасы “Күбәләк” мәктәпкә әзерлек төркеме балалары белән “Өч кыз” татар халык әкиятен сәхнәләштерү.**

Зал өй эче итеп бизәлгән. Түрдә караваt тора, кырыйда комган, ләгән, уртада өстәл.

Автор- Мәйсәрә
әни - Ралина
беренче кыз - Әминә
икенче кыз - Мәрьям
өченче кыз - Сәфинә
тиен - Ильяс
аю - Сулейман
куян -Данияз
куян - Тахир
бүре - Рияз
төлке - Зунайра

аю- Узаирбек

Автор (Мәйсәрә), кырыйдан әкиятне укып башлап җибәрә.

-Борын-борын заманда булган икән ди бер хатын. Әни (Ралинә) кеше чыга, себерке алып идән себерә. Анын булган ди өч кызы. (Өч кыз чыгып уйныйлар, Беренче кыз (Әминә) белән өченче кыз (Сәфинә) туплы уйный, ә икенче кыз (Мәрьям) сикергеч белән сикерә.)

**Автор:** Менә бер ел уткән. 2,3 ел үткән. Әниләре авырып киткән.

Ул тиен дустын чакырган.

**Әни**: Тиен дустым, барсана кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәр.

**Тиен**: Ярар, хәзер, дустым борчылма, ятып хәл җый.

**Автор:** Тиен шундук чыгып чапкан.

Әнинең авыруын бар урман җәнлекләре ишеткән. Иң беренче Аюлар (Сөләйман белән Узаирбек) бал күтәреп килгән.

**Аю**: - Исәнмесез, бал 1000 авыруга ярдәм итә, терелегез тизрәк.

**Автор**: Аннан бүре килгән, бер кәрзин дару үләннәре бүләк иткән.

**Бүре**: Мәтрүшкәнең файдасы күп, чәйгә салып эчегез, терелерсез.

**Автор**:Төлке алма, гөмбәләр китергән.

**Төлке:** Исәнмесез, сыйланыгыз.

**Автор**: Куяннар кишер алып килгәннәр.

**Куяннар**: Кишер ул витаминга бай, үзебез үстердек, аша апа.

**Автор**: Тиен беренче кызга тәрәзә каккан.

**Тиен:** Синең әниең авырып китте.

**Олы кыз:** Бик барыр идем дә җиз ләгәннәремне юасым бар.

**Тиен**:Алайса, гомерең буе ләгәннәрең белән кал.

**Автор**: Олы кыз гөберле бакага әверелгән.(Бака уенчыгы пәйдә була)

Тиен икенче кызга йөгергән. Ишеген шакылдаган.

**Икенче кыз:** Кем бар анда?

**Тиен:** Бу мин Тиен, синең әниең авырып китте, сине чакырды.

**Икенче кыз**:Бик барыр идем, тик җепләрне ярминкәгә өлгертәсем бар.

**Тиен**: Алайса, бу җепләрең белән гомерлеккә кал.

Автор: Икенче кыз үрмәкүчкә әйләнгән. (үрмәкүч уенчыгы пәйдә була)

Автор: Тиен өченче кызга йөгергән.

**Тиен:** Бу мин Тиен, синең әниең авырта, сине чакырды.

**Автор**: Камырлы кулларын да юып тормыйча кечкенә кыз әнисе янына йөгергән. Әнисенә дарулар биргән, тиен чәй эчерткән. Өйләрен җыйган. Әнисе, кечкенә кыз,Тиен рәхәт гомер иткәннәр.

## Кушымта № 8

**Театр эшчәнлеге буенча диагностика.**

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның, театр эшчәнлеге буенча, белем һәм күнекмәләр дәрәҗәсенең үсешен билгеләү диагностикасы Е. В. Мигунованың методикасы буенча үткәрелә.

(“Балалар бакчасында театраль педагогика” методик киңәшләр китабы)

**Театр культурасының нигезләре:**
**Югары дәрәҗә** (3 балл):
театр сәнгатенә һәм театр эшчәнлегенә ныклы кызыксыну чагыла; театрда үз – үзен тоту кагыйдәләрен белә; театрның төрләрен атый, аларның аермаларын таба һәм театр өлкәсендәге һөнәрләр турында белеме бар;
**Уртача дәрәҗә** (2 балл): театр эшчәнлеге белән кызыксына, үзенең белемнәрен театр эшчәнлегендә куллана.
**Түбән дәрәҗә** (1 балл): театр эшчәнлегенә кызыксынуы юк; театрда үз – үзен тоту кагыйдәләрен белә; театрның төрләрен атауда кыенлыклар кичерә.

**Сөйләм теле культурасы**
**Югары дәрәҗә** (3 балл): әдәби әсәрнең төп идеясен аңлый, үз фикерен башкаларга җиткерә белә; төп һәм иярчен геройларга тулысы белән сүзле характеристика бирә; әдәби әсәрне сәнгатьле итеп, дөрес интонация белән сөйли ала.
**Уртача дәрәҗә** (2балл): Әдәби әсәрнең төп идеясен аңлый; төп һәм иярчен геройларга сүзле характеристика бирә; сөйләмендә тел сәнгатенең чараларын куллана (эпитет, чагыштыру)
**Түбән дәрәҗә** (1балл): Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген аңлый; төп һәм иярчен геройларны аера; әдәби әсәрне тәрбияче ярдәмендә генә сөйли.

**Эмоциональ – образлы үсеш.**
**Югары дәрәҗә** (3 балл**):** Әкият геройларының хис – кичерешләрен, холык – фигыльләрен дөрес тасвирлый белә, әкиятне сәхнәләштергәндә уңышлы куллана.
**Уртача дәрәҗә** (2 балл): мимика , кул хәрәкәте, гәүдә хәрәкәте кулланып, әкият геройларының хис – кичерешләрен, холык – фигыльләрен тасвирлый белүдә белеме бар, сәнгатьлелек өлкәсендә ярдәм таләп ителә.
**Түбән дәрәҗә** (1 балл): эмоиональ халәтләрне аера, ләкин мимика, кул хәрәкәте, гәүдә хәрәкәте аша геройларны чагылдырганда кыенлыклар кичерә.

**Курчак йөртү күнекмәләре.**
**Югары дәрәҗә** (3 балл**):** спектакль өстендә эшләгәндә курчаклар белән идарә итүнең төрле төрләрен куллана.
**Уртача дәрәҗә** (2 балл): спектакль өстендә эшләгәндә курчакларны йөртү күнекмәләрен куллана.
**Түбән дәрәҗә** (1 балл): курчаклар белән идарә иткәндә иң гади күнекмәләрдән файдалана.

**Музыкаль үсеш**
**Югары дәрәҗә** (3 балл**):** төрле характердагы музыкага карап сәнгатьле пластик образлар тудыра; спектакльга мөстәкыйль рәвештә музыкаль бизәлеш куллана, сәхнәдә иркле җырлый, бии.

**Уртача дәрәҗә** (2 балл): ирекле пластик хәрәкәтләр аша музыканың характерын билгели, тәрбияче ярдәмендә музыкаль бизәлешне сайлый; сәхнәдә ирекле җырлый, бии.
**Түбән дәрәҗә (**1 балл): төрле характердагы музыкага карап сәнгатьле пластик образлар тудыруда һәм спектакльгә музыка сайлаганда кыенлыклар кичерә.

**Иҗади - бизәлеш эшчәнлегенең нигезе**
**Югары дәрәҗә** (3 балл**):** спектакльнең эчтәлеге буенча мөстәкыйль рәвештә рәсем иҗат итә; төрле төрдәге театрлар өчен (курчак, бармак, өстәл, фланель) декорацияләр һәм персонажлар әзерләү эше буенча осталыгын күрсәтә.
**Уртача дәрәҗә** (2 балл): төрле төрдәге театрлар өчен (курчак, бармак, өстәл, фланель) декорацияләр һәм персонажлар әзерләү эшендә катнаша, эскизлар һәм сүзле инструкция буенча төрле материаллардан декорацияләр тудыра.
**Түбән дәрәҗә** (1 балл): декорацияләр һәм персонажлар әзерләү эше буенча кыенлыклар кичерә, спектакльдә барган төп күренешләрне чагылдырган рәсемнәр ясый.

**Коллектив эшчәнлек нигезләре**
**Югары дәрәҗә** (3 балл**):** спектакль буенча эш этапларында иҗади активлык күрсәтә, сәхнәдә бер –берсе белән үзара аңлашып эшләү күнекмәләрен уңышлы куллана.
**Уртача дәрәҗә** (2 балл): сәхнәдә бер –берсе белән үзара аңлашып эшләү күнекмәләрен куллана.
**Түбән дәрәҗә** (1 балл):спектакль эшчәнлегендә катнашырга теләк белдерми.

**Гомуми үсеш.**
**Югары дәрәҗә (18 - 20 балл)-** Театр сәнгатенә һәм театр эшчәнлегенә ныклы кызыксыну чагыла; театрда үз – үзен тоту кагыйдәләрен белә. Театрның төрләрен атый, аларның аермаларын таба һәм театр өлкәсендәге һөнәрләр турында белеме бар.Әдәби әсәрнең төп идеясен аңлый, үзе фикерен башкаларга җиткерә белә. Төп һәм иярчен геройларга тулысы белән сүзле характеристика бирә.Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп, дөрес интонация белән сөйли ала. Әкият геройларының хис – кичерешләрен, холык – фигыльләрен дөрес тасвирлый белә, экиятне сәхнәләштергәндә уңышлы куллана. Спектакль өстендә эшләгәндә курчаклар белән идарә итүнең төрле төрләрен куллана. Төрле характердагы музыкага карап сәнгатьле пластик образлар тудыра; спектакльгә мөстәкыйль рәвештә музыкаль бизәлеш куллана, сәхнәдә ирекле җырлый, бии. Төрле төрдәге театрлар өчен (курчак, бармак, өстәл, фланель) декорацияләр һәм персонажлар әзерләү эше буенча осталыгын күрсәтә. Спектакль буенча эш этапларында иҗади актив, сәхнәдә бер –берсе белән үзара аңлашып эшләү күнекмәләрен уңышлы куллана.

**Уртача дәрәҗә (11 - 17 балл)-** Театр эшчәнлеге белән кызыксына, үзенең белемнәрен театр эшчәнлегендә куллана. Әдәби әсәрнең төп идеясен аңлый. Төп һәм иярчен геройларга сүзле характеристика бирә ала. Сөйләмендә тел сәнгатенең чараларын куллана (эпитет, чагыштыру). Мимика , кул хәрәкәте, гәүдә хәрәкәте кулланып, әкият геройларының хис – кичерешләрен, холык – фигыльләрен тасвирлый белүдә белеме бар, сәнгатьлелек өлкәсендә ярдәм таләп ителә. Спектакль буенча эшләгәндә курчаклар белән идарә итү кагыйдәләрен белә. Пластик хәрәкәтләр аша музыканың характерын билгели, тәрбияче ярдәмендә музыкаль бизәлеш сайлый.Сәхнәдә ирекле җырлый, бии. Төрле төрдәге театрлар өчен (курчак, бармак, өстәл, фланель) декорацияләр һәм персонажлар әзерләү эшендә катнаша, эскизлар һәм сүзле инструкция буенча төрле материаллардан декорацияләр тудыра. Сәхнәдә бер –берсе белән үзара аңлашып эшләү күнекмәләрен куллана.
**Түбән дәрәҗә (7 - 10 балл) -** Театр эшчәнлегенә кызыксынуы аз. Театрда үз – үзен тоту кагыйдәләрен белә. Театрның төрләрен атауда кыенлыклар кичерә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген аңлый, төп һәм иярчен геройларны аера, әдәби әсәрне тәрбияче ярдәмендә генә сөйли. Эмоциональ халәтләрне аера, ләкин мимика, кул хәрәкәте, гәүдә хәрәкәте аша геройларны чагылдырганда кыенлыклар кичерә. Курчаклар белән идарә иткәндә иң гади күнекмәләрдән файдалана. Төрле характердагы музыкага карап сәнгатьле пластик образлар тудыруда һәм спектакльгә музыка сайлаганда тәрбияче ярдәменнән файдалана. Декорацияләр һәм персонажлар әзерләү эше буенча кыенлыклар кичерә. Спектакль эшчәнлегендә катнашырга теләк белдерми.